**Манзарас авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**2022 елның 21 сентябреннән** **№ 22**

Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Кәчимир авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Кәчимир авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы Кәчимир авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Манзарас авыл җирлеге Уставының 20 ст. нигезендә Манзарас авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 2 октябренә 10 сәгать 00 минутка беренче этапта, 2022 елның 2 октябренә 18 сәгать 00 минутка икенче этапта «Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Кәчимир авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы Кәчимир авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Кәчимир авылы, Таҗетдинов ур., 36а адресы буенча үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Кәчимир авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы Кәчимир авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацны өстәргә:

-Чишмә территориясен ремонтлау, карап тоту һәм төзекләндерү; самавыр сатып алу һәм урнаштыру; ясалма сулык булдыру, проект-смета документациясен эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р.Г. Хәбибуллина